ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Уен бизнесына салым ставкалары турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Уен бизнесына салым ставкалары турында” 2012 елның 24 февралендәге 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2 статья. **Уен бизнесына салым ставкалары**

Уен бизнесына салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

1) букмекерлык конторасының бер процессинг үзәге өчен – 250 000 сум;

2) тотализаторның бер процессинг үзәге өчен – 250 000 сум;

3) тотализаторның интерактив ставкалар кабул итү буенча бер процессинг үзәге өчен – 3 000 000 сум;

4) букмекерлык конторасының интерактив ставкалар кабул итү буенча бер процессинг үзәге өчен – 3 000 000 сум;

5) тотализаторның ставкалар кабул итү буенча бер пункты өчен – 14 000 сум;

6) букмекерлык конторасының ставкалар кабул итү буенча бер пункты өчен – 14 000 сум.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай үткәч, әмма уен бизнесына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2017 ел, 22 декабрь
№ 95-ТРЗ